Укыту-методик комплектында тупланган материаллар балалар бакчасы педагогларына балаларның сөйләмен үстерү, тирә-юнь, матур әдәбият әсәрләре белән таныштыру максатында гына түгел, ә рәсем ясау, әвәләү, кул хезмәте, конструкцияләү, эксперимент эшләре, кисеп ябыштыру, музыка, физкультура шөгыльләрендә, иртән балаларны кабул итү, саф һавада булу, табигатьне күзәтү вакытында, әти-әниләр белән бердәм эшчәнлектә иҗади якын килеп кулланыла һәм ныгытыла.

«Туган телдә сөйләшәбез» методик кулланмасы балаларга телебезнең матурлыгын, байлыгын аңларга, аны сиземләргә, үзләрендә күркәм сыйфатлар булдырырга, тел хәзинәсен тирәнтен аңларга, кеше өчен газиз булган туган җиргә, туган телебезгә мәхәббәт, әти-әниләргә, өлкәннәргә карата хөрмәт, итәгать тәрбияләү, үзләрендә хезмәт сөю, тыйнаклык, шәфкатьлелек кебек күркәм сыйфатлар булдырырга ярдәм итә.

Балалар «сүз», «аваз» терминнарының мәгънәсен дөрес итеп аңлый һәм куллана башлау, сүзгә игътибарлары арту, яңгырашы буенча охшаш һәм төрле сүзләрне табу, сүзләрдәге кирәкле авазларны аерып күрсәтә.

Туган телгә өйрәтү, сөйләм үстерү бурычларын чишү өйрәтүнең төрле методлары, алымнары, чаралары куллану. Алты яшьтәге балалар белән оештырылган эшчәнлек уен характерын ала.

Өйрәтү-тәрбия процессында балалар белән эшчәнлекне оештырганда тәрбиячегә иҗади якын килү мөмкинлеге бирелә. Эшчәнлек конспектларын төзегәндә тәрбияче өчен күрсәтмәләр, балаларның якынча җаваплары, балаларны активлаштыру җәя эчендә күрсәтелә. Җәя эчендә бирелгән индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар истә калдыру максатыннан аваз, сүз, иҗек, фраза кебек сөйләм элементын кабатлауны күрсәтү.

**Белем бирү эшчәнлегенең нәтиҗәләре:**

Бала сәламәт яшәү рәвеше, дөрес туклану турында күзаллый.

Табигатьнең төрле объектлары турында мәгълүмәт бирә ала.

Үзе, әти-әнисе турында сөйли белә.

Үзенең адресын, телефон номерын әйтә белә.

Бала күмәк сөйләмдә актив катнаша.

Сөйләмдә төрле сүз төркемнәрен аңлап, төгәл куллана ала.

Предметлар, картиналар, рәсемнәр буенча иҗади хикәя төзи белә.

Әсәрнең жанрын билгели ала (әкият, хикәя, шигырь).

Китап геройларына карата үз мөнәсәбәтен белдерә ала.

Шигырьләрне, сәхнәләштергән әсәрләрне сәнгатьле итеп сөйли.

Китаплардан яңа белемнәр алу мөмкинлеген аңлый.

**Тәрбияче һәм ата-аналар белән берлектә ирешергә кирәк нәтиҗәләр:**

Сәламәт яшәү рәвеше, дөрес туклану турында бала күзалламый.

Табигатьнең төрле объектлары турында мәгълүмат бирә алмый.

Үзе (фамилиясе, исеме, адресы, телефон номеры, әти-әнисе) турында мәгълүматы аз.

Бала күмәк сөйләмдә катнашмый.

Предметлар, картиналар, рәсемнәр буенча үзлектән хикәяләр төземи.

Бала әсәрнең жанрын (әкият, хикәя, шигырь) тәрбияче ярдәменнән башка билгели алмый.

Китап геройларының кылган гамәлләренә дөрес бәя бирә алмый.

Шигырьләрне тиз истә калдырмый, сәнгатьле итеп сөйли алмый.

Эчтәлеге буенча сорауларга тәрбияче ярдәмендә җавап бирә яки бирә алмый.

Китаплар белән кызыксынмый.

### 1.6. Төркемнәрнең исемлеге һәм милли составы (кушымтада)

## II. Эчтәлек бүлеге (содержательный раздел)

### 2.1. Кечкенәләр төркеме (3-4 яшь)

**«Туган телдә сөйләшәбез» (икенче вариант), кечкенәләр төркемендә (3-4 яшь) тәрбияләнүче татар балаларына ана теле өйрәтү, өчен комплекслы тематик план**

| **Үткәрү вакыты** | **Проект, режим вакытында уен эшчәнлеге темалары** |
|---|---|
| Исәнме, балалар бакчасы | |
| Сентябрь<br>I атна | 1.1. Танышу<br>1.2. Өйдә кем яши? Мин малай, мин кыз |
| Сентябрь<br>IIатна | 2.1. Мияу белән танышу<br>2.2. Әйдәгез танышыйк, әйдә дуслашыйк |
| Сентябрь<br>IIIатна | 3.1. Минем яраткан уенчыкларым<br>3.2. Карусельга сәяхәт |
| Уенчыклар | |
| Сентябрь<br>IV атна | 4.1. Без уйнарга яратабыз<br>4.2. Йомшак уенчык карау, туп |

| | |
|---|---|
| Октябрь<br>I атна | 1.1. Туган көн, Мияу кунакка килгән<br>1.2. Уенчыклар кибете |
| Көз | |
| Октябрь<br>II атна | 2.1. Алтын көз, көз килде<br>2.2. Аваз культурасы,Ө авазы |
| Октябрь<br>III атна | 3.1. Куян үстергән кишер һәм помидор<br>3.2. Яшелчә бакчасында, «Шалкан» әкияте |
| Октябрь<br>IV атна | 4.1. Җиләк-җимеш бакчасында<br>4.2. Бакчада алмалар өлгерде, уйный-уйный санийбыз |
| Гаилә | |
| Ноябрь<br>I атна | 1.1. Өйдә кем яши?Безнең гаилә<br>1.2. Әби күчтәнәче |
| Ноябрь<br>II атна | 2.1. Тату гаилә<br>2.2. Минем дуслар, әйдәгез дуслашыйк |
| Ноябрь<br>III атна | 3.1. Минем туганнарым, безнең гаилә<br>3.2. Әби күчтәнәче |
| Ноябрь<br>IV атна | 4.1. Дустыңны сыйла, сөт, чәй<br>4.2. Кунакка барабыз |
| Кыш | |
| Декабрь<br>I атна | 1.1. Кар ява, Алсуны урамга киендерәбез<br>1.2. А. Алиш «Куян кызы» |
| Декабрь<br>II атна | 2.1. «Чанада шуабыз» рәсемен карау<br>2.2. Кышкы уеннар, «Куяннар» уенын өйрәнү |
| Яңа ел бәйрәме | |
| Декабрь<br>III атна | 3.1. Тиздән чыршы бәйрәме,Б. Рәхмәтнең «Кыш бабай» шигырен уку<br>3.2. Уйныйбыз да, җырлыйбыз да |
| Декабрь<br>IV атна | 4.1. Без бәйрәмгә әзерләнәбез, бәйрәм концерты<br>4.2. Яңа ел бәйрәме |
| Минем йортым, минем шәһәрем | |
| Январь<br>II атна | 2.1. Минем шәһәрем<br>2.2. Мин «КамАЗ» оныгы |
| Январь<br>III атна | 3.1. «Әлли-бәлли итәргә... » бишек җыры<br>3.2. Безнең урам |
| Январь<br>IV атна | 4.1. Алсуның яңа өе<br>4.2. Алсуда кунакта |
| Безнең авылда | |
| Февраль<br>I атна | 1.1. «Кем нәрсә ярата?»татар халык әкиятен сөйләү<br>1.2. «Песи һәм песи балалары»рәсемен карау, Җ.Тәрҗемановның»Үзен бик чиста йөртә»шигырен уку |
| Февраль<br>II атна | 2.1. Йорт кошлары, Р.Батулланың «Елак әтәч»әсәрен уку<br>2.2. Без уйныйбыз |
| Ватанны саклаучылар көне | |
| Февраль<br>III атна | 3.1. Зур гаилә, безнең әтиләр һәм абыйлар<br>3.2. Бабайга кунакка барабыз |
| Февраль<br>IV атна | 4.1. Ватанны саклаучылар көне, очучылар<br>4.2. З. Туфайлованың «Шофёр булам» шигырен уку |

| 8 нче март | |
|---|---|
| Март<br>I атна | 1.1. Минем әнием, кояш гомере телим мин, әнием, сиңа!<br>1.2. Без әнигә булышабыз |
| Март<br>II атна | 2.1. Әбигә кунакка барабыз<br>2.2. Мин әнинең ярдәмчесе, Азат кунак чакыра |
| Кыргый хайваннар | |
| Март<br>III атна | 3.1. Урманда, аю белән куян<br>3.2. «Өч аю»әкияте |
| Әкияттә кунакта | |
| Март<br>IV атна | 4.1. «Теремкәй» рус халык әкиятен сөйләү, кыргый хайваннар<br>4.2. «Төлке, куян һәм әтәч» әкиятен сәхнәләштерү |
| Яз | |
| Апрель<br>I атна | 1.1. Урамда яз, яз җитте<br>1.2. Яз җыры |
| Апрель<br>II атна | 2.1. «Кояш чык, чык, ...»<br>2.1. Язгы күренешләр, ак аю кунакка килгән |
| Апрель<br>III атна | 3.1. Кошлар<br>3.2. Х. Вахитның «Уңган сыерчык» шигырен уку<br>Без уйныйбыз |
| Бәйрәмнәр | |
| Апрель<br>IV атна | 4.1. Бәйрәмгә барабыз<br>4.2. «Балалар бакчасында бәйрәм» дигән рәсем карау, «Урманда зур концерт» анимацион сюжет карау |
| Җәй | |
| Май<br>I атна | 1.1. Автобуста сәяхәт<br>1.2. Җ.Тәрҗемановның «Кикрикүк» шигырен уку, мультфильмда кунакта |
| Май<br>II атна | 2.1. М.Мазуновның «Кәҗә»шигырен уку, «Кәҗә һәм кәҗә бәтиләре»рәсемен карау<br>2.2. Чәчәкләр – тормыш яме |
| Май<br>III атна | 3.1. Матур җәй кил безгә<br>3.3. Мин җәйне яратам, «Карга» эндәшен уку |
| Май<br>IV атна | 4.1. Саф һавада, экология сукмагы буенча сәяхәт<br>4.2. Без уйныйбыз |
| 35 атна | 70 |

## 2.2. Уртанчылар төркеме (4-5 яшь)

**«Туган телдә сөйләшәбез» (икенче вариант) уртанчылар төркемендә (4-5 яшь) тәрбияләнүче татар балаларына ана теле өйрәтү өчен комплекслы тематик план**

| **Үткәрү вакыты** | **Проект,<br>шөгыль, эшчәнлек темалары** |
|---|---|

| | |
|---|---|
| Мин - дөньяның бер кешесе, без балалар бакчасында | |
| Сентябрь<br>I атна | 1.1. Танышу. Без балалар бакчасында<br>1.2. Минем дусларым*(режим вакыты)* |
| Сентябрь<br>II атна | 2.1. Минем туганнарым<br>2.2. Әкиятләр иленә сәяхәт *(режим вакыты)* |
| Сентябрь<br>III атна | 3.1. Әйдәгез, дуслашыйк<br>3.2. Безнең гаилә, әти, әни һәм мин *(режим вакыты)* |
| Сентябрь<br>IV атна | 4.1. Г. Тукай «Безнең гаилә» шигырен уку һәм ятлау<br>4.2. «Гаилә» рәсемен карау *(режим вакыты)* |
| Күз, күз күчтәнәчләре | |
| Октябрь<br>I атна | 1.1. Көз килде. «Көз»рәсемен карау (әйе, юк)<br>1.2. Җимешләр *(режим вакыты)* |
| Октябрь<br>II атна | 2.1. Әйдәгез уйныйбыз<br>2.2. Яшелчәләр, «Көз һәм балалар» җыры*(режим вакыты)* |
| Октябрь<br>III атна | 3.1. Әбинең күчтәнәчләре<br>3.2. Р. Батулла «Аю Әппәс» әкиятен сөйләү *(режим вакыты)* |
| Октябрь<br>IV атна | 4.1. «Шалкан» әкияте<br>4.2. Анимацион сюжет «Шалкан әкияте буенча»*(режим вакыты)* |
| Табын янында, татар халык ашлары (8) | |
| Ноябрь<br>I атна | 1.1. Ашамлыклар, ипи, сөт<br>1.2. Татар халык ашлары *(режим вакыты)* |
| Ноябрь<br>II атна | 2.1. Рәхмәт әйт<br>2.2. Без кибеткә барабыз, ашамлыклар алабыз *(режим вакыты)* |
| Ноябрь<br>III атна | 3.1. Кунак сыйлау<br>3.2. Аш бүлмәсе *(режим вакыты)* |
| Ноябрь<br>IV атна | 4.1. Табын янында<br>4.2. Дустыңны сыйла (зур, кечкенә) *(режим вакыты)* |
| Безнең уенчыклар | |
| Декабрь<br>I атна | 1.1. Курчак кунакка килгән, уенчыклар белән уйныйбыз<br>1.2. Безнең уенчыклар *(режим вакыты)* |
| Декабрь<br>II атна | 2.1. Яңа уенчыклар, уенчыклар кибете.<br>2.2. Әйдәгез уйныйбыз *(режим вакыты)* |
| Декабрь<br>III атна | 3.1. Алиянең дуслары безгә кунакка килгән<br>3.2. Уйныйбыз *(режим вакыты)* |
| Декабрь<br>IV атна | 4.1. Бездә бәйрәм, яңа ел килә<br>4.2. Минем яраткан уенчыкларым *(режим вакыты)* |
| Кыш | |
| Январь<br>II атна | 2.1. Җәнлекләр кышкы урманда<br>2.2. Күчтәнәчләр. Ә. Бариның «Кыш» шигырен уку *(режим вакыты)* |
| Январь<br>III атна | 3.1. Яңа уенчыклар, кибеткә сәяхәт<br>3.2. Алсуның туган көне *(режим вакыты)* |
| Январь<br>IV атна | 4.1. Уйныйбыз. А. Алиш «Куян кызы»<br>4.2. Хәйдәрнең «Керпе туны» әкиятен уку *(режим вакыты)* |
| Февраль<br>I атна | 1.1. Мияуга бүләк<br>1.2. Качышлы уйныйбыз*(режим вакыты)* |
| Ю | |
| Февраль<br>II атна | 2.1. Бүләкләр<br>2.2. Б. Рәхмәт «Су» шигырен уку, ятлау *(режим вакыты)* |
| Февраль<br>III атна | 3.1. Уенчыклар юабыз, уенчыклар үпкәләгән<br>3.2. «Күңелле уеннар» *(режим вакыты)* |

| Ватанны саклаучылар | |
|---|---|
| Февраль<br>IV атна | 4.1. Безнең Армия. Саннар<br>4.2. Хәрби һөнәрләр (очучылар, солдатлар). К. Булатованың «Солдатлар» шигырен уку *(режим вакыты)* |
| Март<br>I атна | 1.1. Дуслар кунакка килгән, уйнарга чакыр<br>1.2. Иң яхшы әти *(режим вакыты)* |
| Яз, сигезенче март | |
| Март<br>II атна | 2.1. Кар Бабай язны эзли, яз бүләкләре<br>2.2. Уйныйбыз да, саныйбыз да *(режим вакыты)* |
| Март<br>III атна | 3.1. Әнием турында сөйлим<br>3.2. З. Туфайлованың «Әни сүзе» шигырен ятлау *(режим вакыты)* |
| Март<br>IV атна | 4.1. З. Туфайлованың «Әни сүзе» шигырен ятлау<br>4.2. Нур Гайсинның «Яз килә» шигырен уку *(режим вакыты)* |
| Күчмә кошлар | |
| Апрель<br>I атна | 1.1. Бергәләп уйныйбыз. Күчмә кошлар<br>1.2. Б. Рәхмәтнең «Яз» шигырен ятлау *(режим вакыты)* |
| Халык җәүһәрләре | |
| Апрель<br>II атна | 2.1. Кунак чакырабыз<br>2.2. Кунак чакырабыз *(режим вакыты)* |
| Апрель җитсә, исемеңне җырына куша тургай | |
| Апрель<br>III атна | 3.1. Габдулла Тукайның «Кызыклы шәкерт» шигырен уку<br>3.2. Габдулла Тукайның «Гали белән кәҗә» шигырен ятлау *(режим вакыты)* |
| Апрель<br>IV атна | 4.1. Без татарча сөйләшәбез<br>4.2. Без татарча сөйләшәбез *(режим вакыты)* |
| Йорт хайваннары | |
| Май<br>I атна | 1.1. Йорт хайваннары<br>1.2. К. Ушинскийның «Хайваннар бәхәсе» әсәрен уку *(режим вакыты)* |
| Май<br>II атна | 2.1. Бу өйдә кем яши?<br>2.2. Ягымлы сүзләр *(режим вакыты)* |
| Минем дусларым | |
| Май<br>III атна | 3.1. «Торна белән Төлке» әкиятен уку. Җ. Тәрҗемановның «Кикрикүк» шигырен уку<br>3.2. А. Алишның «Чукмар белән Тукмар» әкияте буенча әңгәмә. Без театр уйныйбыз *(режим вакыты)* |
| Сабантуй бәйрәме | |
| Май<br>IV атна | 4.1. Сабантуйга әзерләнәбез, күңелле Сабантуй<br>4.2. Бездә Сабантуй бәйрәме *(режим вакыты)* |
| 35 атна | 70 |

**«Татарча сөйләшәбез»УМКсының,«Минем өем» проекты буенча уртанчылар төркемендә (4-5 яшь) тәрбияләнүче рус телле балаларга татар теле өйрәтү өчен комплекслы тематик план**

Лексик минимум – якынча 62 сүз һәм сөйләм үрнәкләре.

Актив сүзләр: эти, әни, кыз, малай, мин, исәнмесез, сау булыгыз, исәнме, эт, песи, әйе, юк, сау бул, әби, бабай, әйбәт, ипи, алма, сөт, чәй, рәхмәт, мә, тәмле, кил монда, утыр,

бир, аша, эч, туп, зур, кечкенә, матур, курчак, куян, аю, хәлләр ничек?, уйна, пычрак, чиста, ю, бер, ике, өч, дүрт, биш (49 сүз).

Сөйләм үрнәкләре: утырыгыз, бу кем?, кем юк?, син кем?, кем анда?, басыгыз, ал, ничә? нинди? (13 сүз).

Проектның эчтәлеге түбәндәге темалардан тора:

- Гаилә;
- Ашамлыклар;
- Уенчыклар,
- Саннар.

Атна дәвамында егерме минутлык бер шөгыль, режим вакытында бер уен эшчәнлеге оештырыла.

<table>
<tr><th>Үткәрү вакыты</th><th>Тема</th><th>Сүзлек, актив сүзләр</th><th>Сөйләм үрнәге</th><th>Аудиоязма<br>(ИКТ - экранда эш<br>(дәфтәр буенча)<br>Анимацион сюжетлар</th></tr>
<tr><td></td><td colspan="4">Гаилә</td></tr>
<tr><td>Сентябрь<br>Iатна<br>1.1</td><td>Танышу, минем гаиләм</td><td>әти, әни, исәнмесез сау булыгыз</td><td rowspan="7">- Исәнмесез.<br>- Сау булыгыз!<br><br>- Исәнме.<br>- Бу кем?<br>- Кыз, (малай).<br>- Кем юк?<br>- Малай, (кыз).<br>- Син кем?<br>- Мин Коля (Оля).<br>- Мин малай (кыз, әти, әни)<br>- Исәнме, әни (әти, кыз, малай, Мияу, Акбай).<br>- Сау бул, әни (әти, кыз, малай).<br>- Син кем?<br>- Мин Коля (Оля).<br>- Мин малай.<br><br>- Мин песи. Мин Мияу.<br><br>- Мин эт. Мин Акбай.<br>- Кил монда.<br><br>- Син Коля?<br>- Әйе, Коля.<br>- Син малай (кыз)?<br>- Әйе (юк).</td><td rowspan="7">Аудиоязма №1-23<br>Экранда эш (дәфтәр буенча) №1-4<br><br>Анимацион сюжетлар:<br>1. «Әйдәгез, дуслашыйк»<br>2. «Качышлы уйныйбыз»<br>3. «Шалкан»</td></tr>
<tr><td>Сентябрь<br>Iатна<br>1.2<br>(режим вакыты)</td><td>Малай, кыз</td><td>малай,<br>кыз,<br>бу кем?<br>кем юк?<br>исәнме</td></tr>
<tr><td>Сентябрь<br>II атна<br>2.1</td><td>Минем туганнарым</td><td>мин, әти, әни, кыз малай</td></tr>
<tr><td>Сентябрь<br>IIатна<br>2.2<br>(режим вакыты)</td><td>Әйдәгез, танышыйк</td><td>исәнме,<br>мин (Оля, Саша),<br>сау булыгыз,<br>син кем?<br>исәнмесез</td></tr>
<tr><td>Октябрь<br>III атна<br>3.1</td><td>Әби күчтәнәче</td><td>эт,песи,<br>ипи,рәхмәт,<br>мә</td></tr>
<tr><td>Октябрь<br>III атна<br>3.2<br>(режим вакыты)</td><td>Бабай күчтәнәче</td><td>әйе, юк,<br>сау бул,<br>мә, алма,<br>рәхмәт</td></tr>
<tr><td>Октябрь<br>IVатна<br>4.1</td><td>Сөт, чәй</td><td>сөт,чәй,<br>әби, бабай</td></tr>
</table>

<table>
<tr><td>Сентябрь<br>IVатна<br>4.2<br>(режим<br>вакыты)</td><td>Минем<br>дуслар</td><td>хәлләр ничек?<br>әйбәт, эт,<br>песи,<br>кем анда?<br>кил монда</td><td rowspan="5">- Хәлләр ничек?<br>- Әйбәт.<br>- Кем анда?<br>- Мин песи. Мин Мияу.<br>- Кил монда.<br>- Мин эт. Мин Акбай.<br>- Кил монда.<br>- Әби? (әни, бабай, әби, кыз, малай).<br>- Әйе.<br>- Әни? (әти, бабай, әби, кыз, малай).<br>- Юк.<br>- Малай?<br>- Юк, бабай.<br>- Әби?<br>- Әйе, әби.<br><br>- Хәлләр ничек?<br>- Әйбәт.</td><td rowspan="2"></td></tr>
<tr><td>Октябрь<br>Iатна<br>1.1</td><td>Әйе – юк</td><td>әйе, юк,<br>сау бул</td></tr>
<tr><td>Октябрь<br>Iатна<br>1.2<br>(режим<br>вакыты)</td><td>Кунак<br>килгән</td><td>әби, бабай</td><td rowspan="3"></td></tr>
<tr><td>Октябрь<br>IIатна<br>2.1</td><td>Әйдәгез<br>уйныйбыз</td><td>әти, әни,<br>кем юк?</td></tr>
<tr><td>Октябрь<br>IIатна<br>2.2<br>(режим<br>вакыты)</td><td>Безнең<br>кунаклар</td><td>хәлләр ничек?<br>әйбәт</td></tr>
<tr><td colspan="5">Ашамлыклар</td></tr>
<tr><td>Октябрь<br>III атна<br>3.1</td><td>Әби<br>күчтәнәче</td><td>ипи, алма,<br>рәхмәт,<br>мә</td><td rowspan="7">- Мә, ипи (алма).<br>- Рәхмәт, әби.<br><br>- Мә, ипи (алма).<br>- Рәхмәт, бабай.<br><br>- Коля, мә сөт (чәй).<br>- Рәхмәт.<br><br>- ..., мә сөт (чәй).<br>- Рәхмәт.<br><br>- ..., мә сөт (чәй).<br>- Рәхмәт.<br><br>- Мияу, кил монда. Утыр. (Акбай, Коля, Оля)<br><br>- Оля, кил монда. Мә ипи (алма, сөт, чәй). Ипи (алма, сөт, чәй) тәмле (ме)?<br>- Ипи (алма, сөт, чәй)</td><td rowspan="7">Аудиоязма №24-39<br><br>Экранда эш (дәфтәр буенча) №5-10<br>Анимацион сюжетлар:<br>1. «Тәмле» кибетендә»<br>2. «Азат кунак чакыра»</td></tr>
<tr><td>Октябрь<br>III атна<br>3.2<br>(режим<br>вакыты)</td><td>Бабай<br>күчтәнәче</td><td>алма,<br>рәхмәт, мә</td></tr>
<tr><td>Октябрь<br>IVатна<br>4.1</td><td>Сөт, чәй</td><td>сөт, чәй,<br>мә, рәхмәт</td></tr>
<tr><td>Октябрь<br>IVатна<br>4.2<br>(режим<br>вакыты)</td><td>Дустыңны<br>сыйла</td><td>мә, рәхмәт</td></tr>
<tr><td>Ноябрь<br>I атна<br>1.1</td><td>Рәхмәт әйт</td><td>мә, рәхмәт</td></tr>
<tr><td>Ноябрь<br>I атна<br>1.2<br>(режим<br>вакыты)</td><td>Песине<br>сыйла</td><td>тәмле,<br>кил монда,<br>утыр</td></tr>
<tr><td>Ноябрь<br>IIатна<br>2.1</td><td>Кунак<br>сыйлау</td><td>аша, эч,<br>утыр</td></tr>
</table>

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Ноябрь<br>IIатна<br>2.1 | Кунак сыйлау | утыр | тәмле. Рәхмәт.<br>- Мә, тәмле алма (ипи).<br><br>- Мә, ипи (алма) аша.<br>- Мә, сөт (чәй) эч. | |
| Ноябрь<br>II атна<br>2.2<br>(режим вакыты) | Кунакны ашат | аша, эч | | |
| Ноябрь<br>IIIатна<br>3.1 | Чәй табынында | аша, эч | | |
| Уенчыклар | | | | |
| Ноябрь<br>III атна<br>3.2<br>(режим вакыты) | Уенчыклар | бир, туп, зур, кечкенә, бу нәрсә? | - Бу нәрсә?<br>- Туп (курчак, куян, аю).<br>- Нинди туп?<br>- Зур (кечкенә) туп.<br>- Курчак (туп, куян, аю) бир.<br>- Мә, курчак (туп, куян, аю).<br>- Нинди курчак?<br>- Матур курчак.<br>- Бу нәрсә?<br>- Аю (курчак, куян, туп).<br>- Аю (курчак, куян, туп) нинди?<br>- Аю (курчак, куян, туп) зур (матур, кечкенә, әйбәт).<br><br>- Аю (курчак, куян, туп) нинди?<br>- Аю (курчак, куян, туп) зур (кечкенә, матур, әйбәт).<br>- Аю (курчак, куян, туп)?<br>- Әйе.<br>- Курчак (аю, куян, туп)?<br>- Юк.<br>- Бу нәрсә?<br>- Аю (курчак, куян, туп).<br>- Мә, аю (курчак, куян, туп). Уйна.<br><br>- Коля, кил монда. Уйна. | Аудиоязма №40-53<br><br>Экранда эш (дәфтәр буенча) №11-13<br>Анимацион сюжетлар:<br>1. «Паркка сәяхәт»<br>2. «Уенчыклар үпкәләгән»<br>3. «Күңелле уеннар»<br>4. «Акбай һәм Мияу маҗаралары» |
| Ноябрь<br>IVатна<br>4.1 | Зур, кечкенә | матур, курчак, зур, кечкенә, сикер | | |
| Ноябрь<br>IV атна<br>4.2<br>(режим вакыты) | Күңел ачу кичәсе «Туган көн» | куян, аю, туп, песи, эт, машина, шар, сөт, ипи, алма, чәй | | |
| Декабрь<br>Iатна<br>1.1 | Курчак кунакка килгән | әйе, юк, матур, курчак | | |
| Декабрь<br>Iатна<br>1.2<br>(режим вакыты) | Уенчыклар кибете | уйна, курчак, туп, эт, песи, бир | | |
| Декабрь<br>II атна<br>2.1 | Яңа уенчыклар | зур, кечкенә, куян, аю, нинди? | | |
| Декабрь<br>II атна<br>2.2<br>(режим вакыты) | Без уйныйбыз | ю | | |
| Декабрь<br>III атна<br>3.1 | Алиянең дуслары кунакка килгән | пычрак,чиста, матур, аю, курчак,туп,зур, кечкенә, бир, куян | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Декабрь<br>IVатна<br>4.1 | Бездә бәйрәм | матур, аю, курчак,туп,зур, кечкенә, бир, куян | - Оля, кил монда. Уйна.<br>- Аю (курчак, куян, туп) бир.<br>- Аю (курчак, куян, туп) нинди?<br>- Аю (курчак, куян, туп) зур.<br>- Аю (курчак, куян, туп) кечкенә.<br>- Мә, зур аю уйна (курчак, куян, туп).<br>- Мә, кечкенә аю уйна (курчак, куян, туп).<br>- Аю (курчак, куян), кил монда. Аю ю (утыр, эч, аша).<br>- Коля (Оля), аю (курчак, куян, туп) ю.<br>- Туп (курчак, куян, аю) нинди?<br>- Туп (курчак, куян, аю) пычрак (чиста).<br>- Туп ю.<br>- Туп чиста?<br>- Юк, туп пычрак. (Әйе, туп чиста).<br>Ю, ю, ю - туп (курчак, аю, куян) ю. | |
| Декабрь<br>IVатна<br>4.2<br>(режим вакыты) | Чыршы бәйрәме | матур, аю, курчак,туп,зур, кечкенә, бир, куян | | |
| Январь<br>II атна<br>2.1 | Яңа уенчыклар | куян, аю, нинди? | | |
| Январь<br>II атна<br>2.2<br>(режим вакыты) | Уйныйбыз | матур, аю, курчак, туп, зур, кечкенә, бир, куян | | |
| Январь<br>III атна<br>3.1 | Уйныйбыз | матур, аю, курчак, туп, зур, кечкенә, бир, куян | | |
| Январь<br>III атна<br>3.2<br>(режим вакыты) | Без уйнарга яратабыз | матур, аю, курчак, туп, зур, кечкенә, бир, куян | | |
| Январь<br>IVатна<br>4.1 | Мияуга бүләк | матур, аю, курчак, туп, зур, кечкенә, бир, куян | | |
| Январь<br>IVатна<br>4.2<br>(режим вакыты) | Уенчыклар кибете | хәлләр ничек? | | |
| Февраль<br>Iатна<br>1.1 | Бүләкләр | уйна | | |
| Февраль<br>Iатна<br>1.2<br>(режим вакыты) | Әйдә уйныйк | уйна | | |
| Февраль<br>II атна<br>2.1 | Уйна | бир | | |
| Февраль<br>II атна<br>2.2<br>(режим вакыты) | Күңелле уеннар | туп,курчак | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Февраль III атна 3.1 | Уенчыклар юабыз | пычрак, чиста, ю | | |
| Февраль III атна 3.2 (режим вакыты) | Уенчыкны ю | ю | | |
| Февраль IVатна 4.1 | Дуслар кунакка килгән. Уйнарга чакыр | туп, курчак | | |
| Февраль IVатна 4.2 (режим вакыты) | Оляның уенчыклар ы пычранган. Оляга ярдәм ит | песи | | |
| Саннар – 6 сәгать (49-54) | | | | |
| Март Іатна 1.1 | Саннар | бер, ике, өч, дүрт, биш, ничә? | - Ничә?<br>- Бер (ике, өч, дүрт, биш) алма.<br><br>- Ничә малай?<br>- Бер (ике, өч, дүрт, биш) малай.<br>- Ничә кыз?<br>- Бер (ике, өч, дүрт, биш) кыз.<br><br>- Өч?<br>- Юк.<br>- Ике?<br>- Әйе.<br><br>- Ничә аю (туп, курчак, куян)?<br>- Бер (ике, өч, дүрт, биш) аю. | Аудиоязма №54-60<br>Экранда эш (дәфтәр буенча) №14<br>Анимацион сюжетлар:<br>1. «Уйный-уйный саныйбыз» |
| Март Іатна 1.2 (режим вакыты) | Саннар | бер, ике, өч, дүрт, биш, ничә? | | |
| Март II атна 2.1 | Уйныйбыз да саныйбыз да | бер, ике, өч, дүрт, биш, ничә? | | |
| Март II атна 2.2 (режим вакыты) | Уенчыклар | *Сүзлек:* бер, ике, өч, дүрт, биш, зур, кечкенә, матур, чиста, ничә? | | |
| Март III атна 3.1 | Ничә уенчык? | бер, ике, өч, дүрт, биш, ничә? | | |
| Март III атна 3.2 (режим вакыты) | Уйный - уйный саныйбыз | бер, ике, өч, дүрт, биш | | |
| Кабатлау | | | | |
| Март IVатна 4.1 | Бергәләп уйныйбыз | бабай, әби, әти, әни, кыз, малай | | Аудиоязма №61-64<br>Экранда эш (дәфтәр буенча) №16-17 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Март IVатна 4.2 (режим вакыты) | Бергәләп уйныйбыз | бабай, әби, әти, әни, кыз, малай | | Анимацион сюжет «Күңелле ял итәбез» |
| Апрель Iатна 1.1 | Кунак чакырабыз | бабай, әби, әти, әни, кыз, малай, ипи, сөт, чәй, алма, тәмле | | |
| Апрель Iатна 1.2 (режим вакыты) | Күңелле ял итәбез | бабай, әби, әти, әни, кыз, малай, ипи, сөт, чәй, алма, тәмле | | |
| Апрель II атна 2.1 | Без татарча сөйләшәбе з | бабай, әби, әти, әни, кыз, малай, аю, куян | | |
| Апрель II атна 2.2 (режим вакыты) | Без татарча сөйләшәбе з | бабай, әби, әти, әни, кыз, малай, эт, песи, куян, аю, 1, 2,3,4, 5 | | |
| Апрель III атна 3.1 | Бу өйдә кем яши? | бабай, әби, әти, әни, кыз, малай, 1, 2,3,4, 5 | | |
| Апрель III атна 3.2 (режим вакыты) | Уенчыклар илендә | эт, песи, куян, аю, машина, туп, курчак | | |
| Апрель IVатна 4.1 | Ягымлы сүзләр | исәнме-исәнмесез, сау бул-сау булыгыз, рәхмәт | | |
| Апрель IVатна 4.2 (режим вакыты) | Боерыкны аңлау | кил, утыр, сикер, ю, аша, эч, уйна | | |
| Май Iатна 1.1 | Кунаклар чакырабыз | бабай, әби, әти, әни, кыз, малай, ипи, сөт, чәй, алма, тәмле | | |
| Май Iатна 1.2 | Күңелле ял итәбез | бабай, әби, әти, әни, кыз, малай, ипи, | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| (режим вакыты) | | сөт, чәй, алма, тәмле | | |
| Май II атна 2.1 | Без театр уйныйбыз | бабай, әби, әти, әни, кыз, малай, өй | | |
| Май II атна 2.2 (режим вакыты) | Кызыклы уеннар | үткән материалны ныгыту | | |
| Май III атна 3.1 | Минем дуслар | үткән материалны ныгыту | | |
| Май III атна 3.2 (режим вакыты) | Минем дусларым | үткән материалны ныгыту | | |
| Май IVатна 4.1 | Бездә сабантуй | үткән материалны ныгыту | | |
| Май IVатна 4.2 (режим вакыты) | Хуш киләсең, Сабантуй! | үткән материалны ныгыту | | |

## 2.3. Зурлар төркеме (5-6 яшь)

### «Туган телдә сөйләшәбез» (икенче вариант) зурлар төркемендә (5-6 яшь) тәрбияләнүче татар балаларына ана теле өйрәтү өчен комплекслы - тематик план

| **Үткәрү вакыты** | **Проект,<br>шөгыль, эшчәнлек темалары** |
|---|---|
| Яхшы сүз-җан азыгы | |
| Сентябрь<br>I атна | 1.1. Танышу<br>1.2. Ягымлы сүзләр<br>1.3. Кабатлау *(режим вакыты)* |
| А.Алиш иҗаты | |
| Сентябрь<br>II атна | 2.1. А. Алиш - балалар язучысы<br>2.2. А. Алиш «Каз белән аккош»<br>2.3. «Шалкан» әкияте *(режим вакыты)* |
| Хуш киләсең, ямьле көз | |
| Сентябрь<br>III атна | 3.1. Җәйләр үтте, көзләр җитте<br>3.2. Көзге табигать<br>3.3. «Шалкан» әкияте*(режим вакыты)* |
| Көз күчтәнәчләре | |

| | |
|---|---|
| Сентябрь<br>IV атна | 4.1. Яшелчәләр күргәзмәсенә сәяхәт<br>4.2. Сыйлыйбыз<br>4.3. Баллы кишер *(режим вакыты)* |
| Октябрь<br>I атна | 1.1. Түтәлләрдә үсте яшелчә<br>1.2. Бар матур бакча<br>1.3. Яшелчәләр кибете *(режим вакыты)* |
| Мин яратам сине, Татарстан | |
| Октябрь<br>II атна | 2.1. Мин яратам сине, Татарстан<br>2.2. Туган җирем - Татарстан<br>2.3. Уйный-уйный эшлибез *(режим вакыты)* |
| Октябрь<br>III атна | 3.1. Гүзәл туган ягыбыз<br>3.2. Туган ил кайдан башлана?<br>3.3. Төсле туплар *(режим вакыты)* |
| Төсләр дөньясы | |
| Октябрь<br>IV атна | 4.1. Төсләр<br>4.2. Төсләр дөньясы<br>4.3. Юл маҗаралары *(режим вакыты)* |
| Кем эшләми, шул ашамый | |
| Ноябрь<br>I атна | 1.1. Яшелчә салаты<br>1.2. Яшелчәләр юабыз<br>1.3. Уңыш бәйрәме *(режим вакыты)* |
| Җиләк-җимешләр | |
| Ноябрь<br>II атна | 2.1. Җимешләр<br>2.2. Уйныйбыз да, җырлыйбыз да<br>2.3. Кем эшләми, шул ашамый *(режим вакыты)* |
| Минем гаиләм | |
| Ноябрь<br>III атна | 3.1. Безнең гаилә<br>3.2. Әби, бабайларны хөрмәтлик»<br>3.3. Яшелчәләр кибете» *(режим вакыты)* |
| Табын янында | |
| Ноябрь<br>IV атна | 4.1. Савыт-саба кибетенә сәяхәт<br>4.2. Савыт-саба<br>4.3. Ашханә *(режим вакыты)* |
| Декабрь<br>I атна | 1.1. Курчак Алиягә булыш<br>1.2. Чәй табыны<br>1.3. Кибеттә *(режим вакыты)* |
| Киемнәр дә безне бизиләр | |
| Декабрь<br>II атна | 2.1. Кием кешене бизи<br>2.2. «Кием-салым» кибетенә сәяхәт<br>2.3. Кунак килде *(режим вакыты)* |
| Салкын кыш, кышкы уеннар | |
| Декабрь<br>III атна | 3.1. Салкын кыш<br>3.2. Кышкы уеннар<br>3.3. Өстәл театры «Кем нәрсә ярата» *(режим вакыты)* |
| Декабрь<br>IV атна | 4.1. Без суыктан курыкмыйбыз<br>4.2. Кыш<br>4.3. Өстәл театры «Кем нәрсә ярата?» *(режим вакыты)* |
| Январь<br>II атна | 2.1. Кышкы уеннар<br>2.2. Ел фасыллары<br>2.3. Кем нәрсә ярата? *(режим вакыты)* |
| Кунак булсаң-тыйнак бул | |

| | |
|---|---|
| Январь<br>III атна | 3.1. Без ашыйбыз<br>3.2. Мин кунак яратам<br>3. 3. Кем нәрсә ярата? *(режим вакыты)* |
| Киемнәр | |
| Январь<br>IV атна | 4.1. Киенергә ярдәм ит<br>4.2. Милли киемнәр<br>4.3. Курчак Алиягә ярдәм ит *(режим вакыты)* |
| Февраль<br>I атна | 1.1. Киемнәр дә безне бизиләр<br>1.2. Киемнәр дөньясы<br>1.3. «Өч аю» *(режим вакыты)* |
| Йорт җиһазлары | |
| Февраль<br>II атна | 2.1. Матур әдәбият белән таныштыру<br>2.2. Өстәл театры «Өч аю»<br>2.3. Чисталыкта матурлык *(режим вакыты)* |
| Муса Җәлил безнең күңелләрдә | |
| Февраль<br>III атна | 3.1. Муса Җәлил безнең күңелләрдә<br>3.2. Батырлыкта - матурлык<br>3.3. Киемнәр кибете *(режим вакыты)* |
| Кояш гомере телим мин, әнием, сиңа | |
| Февраль<br>IV атна | 4.1. Без әни белән кибеткә бардык<br>4.2. Әниләр бәйрәме<br>4.3. Без киенәбез *(режим вакыты)* |
| Март<br>I атна | 1.1. Әни кирәк»<br>1.2. Әниемнең тәмле ашлары<br>1.3. Курчакка булышабыз *(режим вакыты)* |
| Без язны яратабыз | |
| Март<br>II атна | 2.1. Яз килә<br>2.2. Яз килә, яз!<br>2.3. Кибеттә *(режим вакыты)* |
| Март<br>III атна | 3.1. Татар халык иҗаты аша язны тасвирлау<br>3.2. «Нәүрүз» – яз бәйрәме<br>3.3. Ягымлы сүзләр *(режим вакыты)* |
| Безнең канатлы дусларыбыз | |
| Март<br>IV атна | 4.1. Күчмә кошлар<br>4.2. Кошлар<br>4.3. Күңелле уенчыклар *(режим вакыты)* |
| Габдулла Тукай иҗаты | |
| Апрель<br>I атна | 1.1. Габдулла Тукай<br>1.2. Г. Тукайның «Кызыклы шәкерт» шигырен уку. Тукай әсәрләреннән төзелгән мультфильмнардан өзекләр карау<br>1.3.«Маша һәм өч аю» *(режим вакыты)* |
| Апрель<br>II атна | 2.1. Г. Тукай «Безнең гаилә», «Гаилә» рәсемен карау<br>2.2. Г. Тукай «Бала белән күбәләк»<br>2.3. «Киемнәр нигә югалган» *(режим вакыты)* |
| Чисталыкта-матурлык | |
| Апрель<br>III атна | 3.1. Саулык-зур байлык<br>3.2. Шигырь уку. Ә. Ерикәй «Чисталык сөябез»<br>3.3. Уенчыклар иленә сәяхәт *(режим вакыты)* |
| Җиңү алып килде май | |

| | |
|---|---|
| Апрель<br>IV атна | 4.1. Сугыш ветераннары белән очрашу<br>4.2. Курчакның туган көне<br>4.3. *(режим вакыты)* |
| Кунак көтәбез | |
| Май<br>I атна | 1.1. Винни-пух кунакка бара<br>1.2. Чебурашка<br>1.3. Син нәрсә яратасың? *(режим вакыты)* |
| Хәрәкәттә-бәрәкәт | |
| Май<br>II атна | 2.1. Минем яраткан спорт төре, шигырь уку. В. Хәйруллина «Туплар»<br>2.2. Кем нәрсә ярата?<br>2.3. Арыслан баласы һәм ташбака ничек җыр җырлаган, яраткан мультфильмнар*(режим вакыты)* |
| Чәчәкле җәй | |
| Май<br>III атна | 3.1. Чәчәкләр-тормыш яме<br>3.2. Чәчәкле җәй<br>3.3. Театр уйныйбыз *(режим вакыты)* |
| Күңелле сабантуй | |
| Май<br>IV атна | 4.1. Күңелле Сабантуй уеннары<br>4.2. Сабан туена әзерлек<br>4.3. Бүген бездә сабантуй *(режим вакыты)* |
| 35 атна | 105 |

**«Татарча сөйләшәбез» УМКсының, «Уйный-уйный үсәбез» проекты буенча зурлар төркемендә (5-6 яшь) тәрбияләнүче рус телле балаларга татар теле өйрәтү өчен комплекслы тематик план**

Актив сүзләр: кишер, нинди?, баллы, ничә?, суган, бәрәңге, алты, җиде, сигез, тугыз, ун, кыяр, кәбестә, кызыл, сары, яшел, кирәк, юа, нәрсә кирәк?, аш, ботка, кашык, тәлинкә, чынаяк, зәңгәр, күлмәк, чалбар, ки, сал, йокла, бит, кул, өстәл, урындык, карават, яратам, бар (38 сүз)

Сөйләм үрнәкләре:бу нәрсә?, хәерле көн, нәрсә бар?, күп (7 сүз).

Проектның эчтәлеге түбәндәге темалардан тора:

- Яшелчәләр;
- Ашамлыклар;
- Савыт-саба;
- Киемнәр;
- Шәхси гигиена;
- Өй җиһазлары;
- Бәйрәм «Туган көн»;
- Бәйрәм «Сабан туй»;

Уртанчылар төркемендәге темалар (гаилә, ашамлыклар, уенчыклар, саннар) ел дәвамында кабатлана.

Атнага егерме бишәр минутлык ике шөгыль, режим вакытында бер уен эшчәнлеге оештырыла.

| **Үткәрү вакыты** | **Тема** | **Сүзлек, актив сүзләр** | **Сөйләм үрнәге** | **Аудиоязма (ИКТ - экранда эш (дәфтәр буенча) Анимацион сюжетлар** |
|---|---|---|---|---|

<table>
<tr><td colspan="5">Кабатлау</td></tr>
<tr><td>Сентябрь<br>I атна<br>1.1</td><td>Минем<br>өем</td><td>әти, әни, кыз,<br>малай, әби, бабай,<br>кил монда</td><td>«Минем өем» проекты<br>буенча</td><td>Аудиоязма №1<br>Экранда эш (дәфтәр<br>буенча) №1<br>Анимацион сюжет:<br>1. «Шалкан»</td></tr>
<tr><td colspan="5">Яшелчәләр</td></tr>
<tr><td>Сентябрь<br>Iатна<br>1.2</td><td>Шалкан<br>әкияте</td><td>шалкан, әти, әни,<br>кыз, эт, малай,<br>песи, әби, бабай</td><td rowspan="10">- Бу нәрсә?<br>- Кишер.<br>- Мә, кишер.<br><br>- Нинди кишер (суган,<br>бәрәңге, кәбестә, кыяр)?<br>- Зур (кечкенә) кишер<br>(суган, бәрәңге, кәбестә,<br>кыяр)<br>- Мә, зур (кечкенә)<br>кишер (суган, бәрәңге,<br>кәбестә, кыяр)<br>- Рәхмәт.<br><br>- Зур кишер (суган,<br>бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>- Кечкенә кишер (суган,<br>бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>- Чиста кишер (суган,<br>бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>- Пычрак кишер (суган,<br>бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br><br>- Кишер (суган, бәрәңге,<br>кәбестә, кыяр) нинди?<br>- Кишер (суган, бәрәңге,<br>кәбестә, кыяр) тәмле, зур<br>(кечкенә), матур, чиста<br>(пычрак)<br><br>Кишер баллы.<br>Алма баллы.<br>- Мә кишер (алма), аша.<br>Баллы?<br>- Әйе, баллы. Рәхмәт.</td><td rowspan="10">Аудиоязма №2-24<br><br>Экранда эш (дәфтәр<br>буенча) №2-6<br><br>Анимацион<br>сюжетлар:<br>1. «Баллы кишер»<br>2. «Уйный-уйный<br>эшлибез»<br>3. «Юл маҗаралары»<br>4. «Кем эшләми, шул<br>ашамый»</td></tr>
<tr><td>Сентябрь<br>Iатна<br>1.3<br>(режим<br>вакыты)</td><td>Шалкан<br>әкияте</td><td>әби, бабай, әти,<br>әни, кыз, малай, эт,<br>песи, шалкан.</td></tr>
<tr><td>Сентябрь<br>II атна<br>2.1</td><td>Кишер<br>үстерәбез</td><td>кишер, нинди?</td></tr>
<tr><td>Сентябрь<br>IIатна<br>2.2</td><td>Баллы<br>кишер</td><td>баллы,<br>баллы кишер,<br>баллы алма,<br>зур кишер, тәмле<br>кишер</td></tr>
<tr><td>Сентябрь<br>IIатна<br>2.3<br>(режим<br>вакыты)</td><td>Баллы<br>кишер</td><td>баллы, баллы<br>кишер, баллы алма,<br>зур кишер, тәмле<br>кишер</td></tr>
<tr><td>Сентябрь<br>III атна<br>3.1</td><td>Куян<br>күчтәнәче</td><td>баллы</td></tr>
<tr><td>Сентябрь<br>III атна<br>3.2</td><td>Бар матур<br>бакча</td><td>баллы (тәмле)<br>кишер, баллы алма,<br>зур кишер</td></tr>
<tr><td>Сентябрь<br>III атна<br>3.3<br>(режим<br>вакыты)</td><td>Бар матур<br>бакча</td><td>баллы (тәмле)<br>кишер, баллы алма,<br>зур кишер</td></tr>
<tr><td>Сентябрь<br>IV атна<br>4.1</td><td>Серле<br>кәрзин</td><td>ничә? сана</td></tr>
<tr><td>Сентябрь<br>IVатна<br>4.2</td><td>Бар матур<br>бакча</td><td>баллы кишер,зур,<br>тәмле кишер,<br>бәрәңге, суган,<br>кыяр</td></tr>
</table>

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Сентябрь<br>IVатна<br>4.3<br>(режим вакыты) | Бар матур бакча | баллы кишер,зур, тәмле кишер, бәрәңге, суган, кыяр | - Ничә кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)? Сана.<br>- Ике (1-10) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>- Оля, кил монда. Мә, ике (1-10) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр).<br>- Ике (1-10) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br><br>- Оля, кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер) бир.<br>- Мә, кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә,кишер).<br>- Рәхмәт.<br><br>- Коля, (1-10) кәбестә (суган, бәрәңге, кишер, кыяр) бир.<br>- Мә, (1-10) кәбестә (суган, бәрәңге, кишер, кыяр).<br>- Сау бул, Коля.<br><br>- Ничә кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер)?<br>- Бер (1-10) кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер).<br>- Кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер) пычрак.<br><br>- Кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) кирәк?<br>- Кирәк.<br><br>- Коля, нәрсә кирәк?<br>- Кыяр (суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) кирәк.<br>- Нинди кыяр?<br>- Яшел (тәмле, чиста) кыяр. | |
| Октябрь<br>I атна<br>1.1 | Серле янчык | кызыл, сары, яшел,<br>суган, бәрәңге,<br>1-10 га кадәр санау | | |
| Октябрь<br>Iатна<br>1.2 | Яшелчәләр кибете | нәрсә кирәк?<br>кыяр, суган, кәбестә, бәрәңге | | |
| Октябрь<br>Iатна<br>1.3<br>(режим вакыты) | Яшелчәләр кибете | ю<br>юа, кыяр, суган, кәбестә, бәрәңге | | |
| Октябрь<br>II атна<br>2.1 | Серле кәрзин | кыяр | | |
| Октябрь<br>II атна<br>2.2 | Уйный-уйный эшлибез! | кыяр, суган, кәбестә, бәрәңге, кишер | | |
| Октябрь<br>II атна<br>2.3<br>(режим вакыты) | Уйный-уйный эшлибез! | кыяр, суган, кәбестә, бәрәңге, кишер | | |
| Октябрь<br>III атна<br>3.1 | Без хезмәт яратабыз! | кәбестә, нинди? | | |
| Октябрь<br>IIIатна<br>3.2 | Төсле туплар | кызыл, сары, сикер, туп | | Аудиоязма № 2-24<br><br>ИКТ уен (эш дәфтәре буенча) № 2-6<br><br>Анимацион сюжетлар:<br>1. «Баллы кишер»<br>2. «Уйный-уйный эшлибез»<br>3. «Юл мажаралары»<br>4. «Кем эшләми, шул ашамый» |
| Октябрь<br>IIIатна<br>3.3<br>(режим вакыты) | Төсле туплар | кызыл, сары, сикер, туп | | |
| Октябрь<br>IV атна<br>4.1 | Төсләр дөньясы | кызыл, сары, сикер, туп | | |
| Октябрь<br>IVатна<br>4.2 | Юл мажаралар ы | кызыл, сары, сикер, яшел | | |

<table>
<tr><td>Октябрь<br>IVатна<br>4.3<br>(режим вакыты)</td><td>Юл маҗаралар ы</td><td>кызыл, сары, сикер, яшел</td><td rowspan="11">- Кыяр (суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) пычрак.<br>- Мә, кыяр (суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) ю.<br><br>- Оля кыяр (суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) юа.<br>- Бу туп.<br>- Туп (алма) нинди?<br>- Туп (алма) сары (кызыл, яшел)<br><br>- Нинди туп (алма) юк?<br>- Кызыл (сары, яшел) туп (алма) юк.<br><br>- Кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) кирәк?<br>- Кирәк.<br>- Коля, нәрсә кирәк?<br>- Кыяр (суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) кирәк.<br>- Нинди кыяр?<br>- Яшел (тәмле, чиста) кыяр.<br>- Кыяр (суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) пычрак.<br>- Мә, кыяр (суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) ю.<br><br>- Оля кыяр ( суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) юа.<br>- Коля, нәрсә кирәк?<br>- Кыяр (суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) кирәк.<br>- Нинди кыяр?<br>- Яшел (тәмле, чиста) кыяр.<br>- Зур кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>- Кечкенә кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>- Чиста кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>- Пычрак кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)</td><td rowspan="8"></td></tr>
<tr><td>Ноябрь<br>I атна<br>1.1</td><td>Төсләр дөньясы</td><td>яшел</td></tr>
<tr><td>Ноябрь<br>Iатна<br>1.2</td><td>Уңыш бәйрәме</td><td>нәрсә бар? нәрсә кирәк?</td></tr>
<tr><td>Ноябрь<br>Iатна<br>1.3<br>(режим вакыты)</td><td>Уңыш бәйрәме</td><td>нәрсә бар? нәрсә кирәк?</td></tr>
<tr><td>Ноябрь<br>II атна<br>2.1</td><td>Яшелчә салаты</td><td>кирәк, нәрсә кирәк? нинди?</td></tr>
<tr><td>Ноябрь<br>IIатна<br>2.2</td><td>Кем эшләми, шул ашамый</td><td>нәрсә бар? нәрсә кирәк?</td></tr>
<tr><td>Ноябрь<br>IIатна<br>2.3<br>(режим вакыты)</td><td>Кем эшләми, шул ашамый</td><td>нәрсә бар? нәрсә кирәк?</td></tr>
<tr><td>Ноябрь<br>III атна<br>3.1</td><td>Яшелчә ю!</td><td>юа, су</td></tr>
<tr><td>Ноябрь<br>IIIатна<br>3.2</td><td>Яшелчәләр кибете</td><td>нәрсә кирәк? нинди? ничә?</td><td rowspan="3"></td></tr>
<tr><td>Ноябрь<br>IIIатна<br>3.3<br>(режим вакыты)</td><td>Яшелчәләр кибете</td><td>нәрсә кирәк? нинди? ничә?</td></tr>
<tr><td>Ноябрь<br>IV атна<br>4.1</td><td>Уйныйбыз да, җырлыйбы з да!</td><td>нәрсә бар?</td></tr>
</table>

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | - Кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) нинди?<br>- Кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) тәмле, зур (кечкенә), матур, чиста (пычрак)<br><br>Кишер баллы.<br>Алма баллы.<br>- Мә кишер (алма), аша. Баллы?<br>- Әйе, баллы. Рәхмәт.<br>- Бу туп.<br>- Туп (алма) нинди?<br>- Туп (алма) сары (кызыл, яшел)<br><br>- Нинди туп (алма) юк?<br>- Кызыл (сары, яшел) туп | |
| | | Ашамлыклар | | |
| Ноябрь IVатна 4.2 | Ашханә | аш, ботка, аша, эч | тәмле аш (ботка, сөт, ипи, чәй)<br><br>- Нәрсә кирәк?<br>- Аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге) кирәк.<br>- Нинди аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге)?<br>- Тәмле аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге).<br>- Мә, аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге) аша (эч).<br>- Рәхмәт. Аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге) тәмле. | Аудиоязма №25-29<br><br>Экранда эш (дәфтәр буенча) №7, 8<br><br>Анимацион сюжетлар: «Аш бүлмәсе» |
| Ноябрь IVатна 4.2 (режим вакыты) | Ашханә | аш, ботка, аша, эч | | |
| Декабрь I атна 1.1 | Ашамлыклар | аш, ботка | | |
| Декабрь Iатна 1.2 | Кибеттә | саннар, төсләр, яшелчәләр, ашамлыклар | | |
| Декабрь Iатна 1.3 (режим вакыты) | Кибеттә | саннар, төсләр, яшелчәләр, ашамлыклар | | |
| Декабрь II атна 2.1 | Аю кунакка килгән | аш, ботка, сөт, чәй, ипи, тәмле, баллы | | |
| Декабрь IIатна 2.2 | Кунак килгән | саннар, төсләр, яшелчәләр, уенчыклар | | |
| Декабрь IIатна 2.3 (режим вакыты) | Кунак килгән | саннар, төсләр, яшелчәләр, уенчыклар | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Декабрь III атна 3.1 | Кем нәрсә ярата? | яратам | - Мин алма (ипи, сөт, чәй, ботка, аш, кыяр, кәбестә, бәрәңге, кишер) яратам.<br><br>- Мин Коля(ны) (Оля(ны) яратам.<br><br>- Мин курчак(ны) (аю(ны), песи(не), эт(не), куян(ны) яратам. | Аудиоязма № 50-60<br><br>ИКТ уен (эш дәфтәре буенча) № 16-19<br><br>Анимацион сюжетлар:<br>1. «Туган көн»<br>2. «Кем нәрсә ярата?» |
| Декабрь IIIатна 3.2 | Өстәл театры «Кем нәрсә ярата?» | яратам | | |
| Декабрь IIIатна 3.3 (режим вакыты) | Өстәл театры «Кем нәрсә ярата?» | яратам | | |
| Декабрь IVатна 4.1 | | | | |
| Декабрь IVатна 4.2 | | | | |
| Декабрь IVатна 4.3 (режим вакыты) | | | | |
| Савыт-саба | | | | |
| Гыйнвар II атна 2.1 | Туган көн | кашык, тәлинкә | - Кашык (тәлинкә, чынаяк) бир.<br>- Нинди кашык (тәлинкә, чынаяк)?<br>- Зур (кечкенә, сары, яшел, кызыл, зәңгәр).<br>- Ничә кашык (тәлинкә, чынаяк)?<br>- (1-10 га) кашык (тәлинкә, чынаяк).<br>- Мә, (1-10) кашык(тәлинкә, чынаяк).<br>- Мә, кызыл (сары, яшел, зәңгәр). чынаяк (тәлинкә, чынаяк). | Аудиоязма №30-37<br><br>Экранда эш (дәфтәр буенча) №9, 10<br><br>Анимацион сюжетлар:<br>1. «Өч аю»<br>2. «Чисталыкта - матурлык» |
| Гыйнвар IIатна 2.2 | Курчак Алиягә булыш! | тәлинкә, кашык | | |
| Гыйнвар IIатна 2.3 (режим вакыты) | Курчак Алиягә булыш! | тәлинкә, кашык | | |
| Гыйнвар III атна 3.1 | Чәй табыны әзерлибез | чынаяк | | |
| Гыйнвар IIIатна 3.2 | Өч аю | тәлинкә, кашык, чынаяк | | |
| Гыйнвар IIIатна 3.3 (режим вакыты) | Өч аю | тәлинкә, кашык, чынаяк | | |
| Гыйнвар IV атна | Төсле чынаяклар | зәңгәр | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 4.1 | | | | |
| Гыйнвар<br>IVатна<br>4.2 | Чисталыкта - матурлык | зәңгәр | | |
| Гыйнвар<br>IVатна<br>4.3<br>(режим вакыты) | Чисталыкта - матурлык | зәңгәр | | |
| | Киемнәр | | | |
| Февраль<br>I атна<br>1.1 | Туган көнгә яңа киемнәр | күлмәк | яшел (кызыл, сары, зәңгәр) күлмәк (чалбар).<br><br>чиста күлмәк (чалбар).<br>матур күлмәк (чалбар).<br><br>күлмәк (чалбар) юк.<br><br>- Оля, күлмәк (чалбар) бир.<br>- Нинди күлмәк (чалбар)?<br>- Сары (кызыл, яшел, зәңгәр) күлмәк (чалбар).<br>- Ничә күлмәк (чалбар)?<br>- Бер (1-10) күлмәк (чалбар)<br>- Курчак, чалбар (күлмәк) ки (сал).<br><br>- Оля, чалбар (күлмәк) бир.<br>- Мә, чалбар (күлмәк).<br>- Рәхмәт. Курчак, мә, чалбар (күлмәк) ки (сал). | Аудиоязма №38-43<br><br>Экранда эш (дәфтәр буенча) №11, 12<br><br>Анимацион сюжетлар:<br>1. «Киемнәр кибетендә»<br>2. «Шаян уенчыклар» |
| Февраль<br>Iатна<br>1.2 | Киемнәр кибете | күлмәк, чалбар ки, сал | | |
| Февраль<br>Iатна<br>1.3<br>(режим вакыты) | Киемнәр кибете | күлмәк, чалбар ки, сал | | |
| Февраль<br>II атна<br>2.1 | Курчакны киендер | чалбар | | |
| Февраль<br>IIатна<br>2.2 | Без киенәбез | күлмәк, чалбар, ки, сал | | |
| Февраль<br>IIатна<br>2.3 | Без киенәбез | күлмәк, чалбар, ки, сал | | |
| Февраль<br>III атна<br>3.1 | Киенергә ярдәм ит | ки | | |
| Февраль<br>IIIатна<br>3.2 | Курчакларга булышабыз | күлмәк, чалбар, ки, сал | | |
| Февраль<br>IIIатна<br>3.3<br>(режим вакыты) | Курчакларга булышабыз | күлмәк, чалбар, ки, сал | | |
| Февраль<br>IV атна<br>4.1 | Алия йокларгаҗы ена | сал, йокла | - Курчак, йокла. | |
| Февраль<br>IVатна<br>4.2 | Кибеттә | күлмәк, чалбар, ки, сал, нәрсә кирәк? | | |
| Февраль<br>IVатна<br>4.3 | Кибеттә | күлмәк, чалбар, ки, сал, нәрсә кирәк? | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| (режим вакыты) | | | | |
| Шәхси гигиена | | | | |
| Март<br>I атна<br>1.1 | Хәерле көн | бит, кул,<br>хәерле көн | - Хәерле көн.<br>- Мә су, бит (кул) ю.<br><br>- Бит (кул) чиста.<br><br>- Бит (кул) чиста.<br>- Әйе, бит (кул) чиста. | Аудиоязма № 43, 44-48<br><br>Экранда эш (дәфтәр буенча) №13, 14<br><br>Анимацион сюжет:<br>1. «Ни өчен киемнәр югалган?» |
| Март<br>Iатна<br>1.2 | Ягымлы сүзләр | өйрәнгән лексиканы ныгыту | | |
